**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ЫНДЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 9 август №31

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның бер өлешен гамәлгә ашыру турындагы 2020 елның 17 февралендәге килешүгә үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы 2020 елның 17 февралендәге килешүгә үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә., Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Югары Ындырчы авыл җирлеге Советына бирелә торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы вәкаләтләренең бер өлешен исемлектән төшереп калдыру өлешендә – җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге Советына:

- Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче җирлекнең җирле үзидарә органнарына 2020 елның 17 февралендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советы белән өстәмә килешү төзергә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен өлешчә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советына тапшырыла торган авыл җирлегенең исемлегеннән төшереп калдырырга - җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында (http://apastovo.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Ындырчы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районының**
**Югары Ындырчы авыл җирлеге Башлыгы** **Ф.М.Гәфиятуллин**